

Боек Җинүнен 80 еллыгын тантаналы рәвештә билгеләп үттек. Бу датага күпторле чаралар багышланган иде. Балалар бакчаларыннан башлап, барлык халык бу бәйрәмгә әзерләнде.
Мәсәлән, 2025 елнын 6 маенда «Балаларга Боек Ватан сугышы турында укыйбыз» XVI халыкара акциясендә «БИТ-21» Рузаевка районы Татар Пешлә модель китапханәсе хезмәткәрләре, «Балачак» («Детство») балалар бакчасынын олкән торкеме белән берлектә, акциягә кушылды. Ө Ләмберә районы Пензятка балалар бакчасында әлеге истәлекле датага багышланган тантаналы чара уздырганнар.

Җинү коне - илебездә ин хормәтле бәйрәмнәрнен берсе. Балалар чарада шигырьләр яттан сойләгәннәр, җырлар башкарганнар, матур әдәбият әсәрләренен эпизод-ларын сәхнәләштергәннәр, биегәннәр. «Тор, зур ил», «Катюша», «Җинү коне» кебек хәрби тематикалы җырлар тантаналы чарага якты ноталар керткән. Доньяларыбыз һәрвакыт тыныч булсын! Балаларыбыз, бу бәхетне аларга бүләк иткән кешеләрне белеп һәм истә тотып, тыныч күк астында үссеннәр.
Интернет челтәрдә «Сугыш балалары» акциясендә катнашучылар татар милләтле якташларыбыз турында сойләп килделәр. Берничәсе турында сезгә дә белдерәсе килә: алар безнен яныбызда.




Боек Җинүнен 80 еллыгы алдыннан Кадошкино районы Латышовка авылы китапханәчесе Надия Мансур кызы Байчурина 1940 елда туып Боек Ватан сугышы һәм сугыштан сонгы ел-лар авырлыгын үз җилкәсендә тойган Раилә Абейдулла кызы Алтаеваны Боек Җинүнен юбилее белән котларга килгән.
- Кызганычка каршы, Латышовка авылында Боек Ватан сугышы ветераннары калмады, тыл хезмәтчәннәре һәм сугыш балалары саны кими бара. Мондый очрашулар торган саен кыйммәтлерәк була бара. Сугыш елларында, ачлык һәм курку булуга карамастан, балалар укуларын дәвам иткәннәр, фронтка посылкалар җибәргәннәр, авыр хезмәт

белән Җинүне якынайтып, кырларда эшләгәннәр. Бүген алар ул фаҗигале көннәрнең соңгы шаһитлары. Аларның һәркайсының тарихы уникаль һәм Бөек Ватан сугышының һәм сугыштан соңгы тормышның дәһшәтле көннәре белән бәйле фаҗигале мизгелләр белән тулы, - дип сөйләде Надия Мансур кызы.
Әңгәмәдә Раилә Абейдулла кызы кичергән авырлыклар турында сөйләгән. Олы яшьтә булуына карамастан, Раилә Абейдулла кызы яңалыклар белән кызыксына, газета-китаплар укый.
Надия Мансур кызы, ихтирам йөзеннән, нык сәламәтлек, озын гомер һәм бетмәс-төкәнмәс оптимизм теләп, чәйгә татлы бүләкләр дә тапшырган.

**Наилә НАСЫРОВА**